ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28 июнь 2017 ел № 3899

Башкарма комитетның «2017 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондындагы торак урыннан файдалану (наем өчен түләү), торак урыннарын карау һәм ремонтлау өчен түләү күләме турында» 2016 елның 29 декабрендәге 7163 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 156 маддәсенең 3 бүлеге һәм 158 маддәсенең 4 бүлеге, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү күләмен билгеләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр санлы боерыгы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күп фатирлы йортта гомуми милкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм күп фатирлы йортта гомуми милкәт белән идарә итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча сыйфаты тиешле дәрәҗәдә булмаган һәм (яки) билгеләнгән вакыттан озакка сузылган хезмәт күрсәтелгән һәм эш башкарылган очракта, торак урыннарын карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 нче Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халык хокукларын һәм ихтыяҗларын яклау системасының нәтиҗәлелеген күтәрү чаралары турында» 2010 елның 19 февралендәге 85 нче карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2017 елга Яр Чаллы шәһәре торак фондындагы торак урыннан файдалану (наем өчен түләү), торак урыннарын карау һәм ремонтлау өчен түләү күләме турында» 2016 елның 29 декабрендәге 7163 нче карарына. 1 нче кушымтаны әлеге карарның 1 нче кушымтасында каралганча яна редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Социаль наем килешүләре һәм муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар, күп фатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар кабул итмәгән һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен

билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортларның торак милекчеләре өчен, күп фатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь ресурслар (салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү) өчен түләү күләмен 2 нче, 3 нче кушымталарда каралганча билгеләргә һәм 2017 елның 1 июленнән гамәлгә кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырырга һәм «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2017 елның 28 июнендәге
3899 нчы карарына
1 нче кушымта

2017 елга
социаль наем килешүләре һәм муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар өчен торак урыннарыннан файдалануга түләү (наем өчен түләү), торак урынны карап тотуга түләү күләмен, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен һәм гомуми жыелышта торак урыннарны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләме билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы торак милекчеләре өчен торак урынны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләме

| Т/с | Түләү исеме | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | 01.07.2017 елдан хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак урыннарны наемга алу (наемга алучылар өчен) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 5,95 |
| 2. | Торак фонд белән идарә итү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,85 |
| 3. | Гомуми файдалану урыннарының санитар торышы, шул исәптән: | | |
| | - йорт эчендәге гомуми файдалану урыннарын жыештыру | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,85 |
| | - йорт яны территориясен жыештыру | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,45 |
| | - чүп үткәргечләргә хезмәт күрсәтү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,45 |
| | - дератизация (дезинсекция) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,16 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | - каты конкүреш калдыкларын жыю, чыгару һәм утильләштерү (тариф каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча региональ оператор белән килешү төзегәнгә кадәр гамәлдә) | аена 1 кешегә | 47,5 |
| 4. | Төзелеш корылмаларына һәм биналарның инженерлык системаларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, шул исәптән: | | |
| | - торак биналар һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,30 |
| | - лифтлар | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 3,40 |
| | - йорт эчендәге электр челтәрләре һәм электр җиһазлары | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,92 |
| | - йорт эчендәге газ челтәрләре | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,25 |
| | - торак йортлар эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары (бойлерсыз) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,23 |
| | - торак йортлар эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системалары (бойлерлы) | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,77 |
| | - йорт эчендәге үзәктән җылыту челтәрләре | аена гомуми торак мәйданының кв.м | 2,78 |
| | коллектив телевидение кабул итү системалары (СКПТ) | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена гомуми торак мәйданының кв.м | 0,55 |
| | - янгынга каршы автоматика системалары | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена гомуми торак мәйданының кв.м | 1,05 |
| | - домофоннар | хезмәт күрсәтелгән очракта, аена фатирдан | 25,00 |

Искәрмә:

Халыкка торак урынны карап тоту һәм ремонтлау хезмәте күрсәтү өчен түләү күләме өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча билгеләнгән.

Домофоннарга хезмәт күрсәтү, лифтларны агымдагы ремонтлау һәм аларга техник хезмәт күрсәтү, каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һәм утильләштерү өчен түләү күләме («Чистый город А» ҖЧҖ, «Чистый город К» ҖЧҖ, «Чистый город Ц» ҖЧҖ, «ПЭК регион 2» ҖЧҖ өчен өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алмыйча, «Мехуборка Закамье» ҖЧҖ, «ПЭК» ҖЧҖ өчен өстәмә кыйммәткә салымны исәпкә алып).

Түләү хезмәт күрсәтелгән очракта алына.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова

Башкарма комитетның
2017 елның 28 июнендәге
3899 нчы карарына
2 нче кушымта

Социаль наем килешүләре һәм муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар, күп фатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар кабул итмәгән һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортларның торак милекчеләре өчен күп фатирлы йортта гомуми милекне карап тоту максатларында коммуналь ресурслар (электр белән тәэмин итү) өчен түләү күләме

| № | | № | Күп фатирлы йортның гомуми милкәте булып саналган җиһаз төркемнәре | Этажлар саны | Торак мәйданының кв.метрына тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | Лифтлар белән җиһазландырылмаган һәм кайнар су белән тәэмин итү максатлары өчен электр белән җылыту һәм электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазландырылмаган күп фатирлы йортлар | 1.1 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр булган лампалардан (подъезд эчендә һәм подъезд өстендә), егәрлеге 60 Вт. югары булган, йорт читтәрләреннән тәэмин ителә торган йорт яны территориясен яктырту лампаларыннан файдаланып яктырту һәм башка җиһаз | 1-5 | 0,05 |
| | | 1.2 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр булган лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары, насос җиһазы (2 насос) һәм башка җиһаз | 1-5 | 0,64 |
| | | | | 6-9 | 0,66 |
| | | 1.3 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары һәм егәрлеге 60 Вт. югары булган, йорт читтәрләреннән тәэмин ителә торган йорт яны территориясен яктырту лампалары, насос җиһазы (2 насос) һәм башка җиһаз | 1-5 | 0,96 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 1.4 | Энергия саклаучы лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары, насос җиһазы (3 һәм күбрәк насос) һәм башка җиһаз | 1-5 | 0,59 |
| | | 1.5 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр булган лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары, насос җиһазы (3 һәм күбрәк насос) һәм башка җиһаз | 1-5 | 0,72 |
| | | 1.6 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары һәм егәрлеге 60 Вт. югары булган, йорт челтәрләреннән тәэмин ителә торган йорт яны территориясен яктырту лампалары, насос җиһазы (3 һәм күбрәк насос) һәм башка җиһаз | 1-5 | 1,0 |
| 2 | Лифтлар белән җиһазландырылган һәм кайнар су белән тәэмин итү максатлары өчен электр белән ягу һәм электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазландырылмаган күп фатирлы йортлар | 2.1 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр булган лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары, насос җиһазы (1 насос), лифтларның энергия бирү җиһазы һәм башка җиһаз | 10 һәм күбрәк | 0,92 |
| | | 2.2 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр булган лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары, насос җиһазы (2 насос), лифтларның энергия бирү җиһазы һәм башка җиһаз | 6-9 | 1,23 |
| | | | | 10 һәм күбрәк | 1,00 |
| | | 2.3 | Энергия саклаучы лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары, насос җиһазы (3 һәм күбрәк насос), лифтларның энергия бирү җиһазы һәм башка җиһаз | 6-9 | 1,13 |
| | | | | 10 һәм күбрәк | 1,22 |
| | | 2.4 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр булган лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары, насос җиһазы (3 һәм күбрәк насос), лифтларның энергия бирү җиһазы һәм башка җиһаз | 6-9 | 1,34 |
| | | | | 10 һәм күбрәк | 1,44 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2.5 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр лампалардан файдаланып подъездны һәм подъезд өстен яктырту җайланмалары һәм егәрлеге 60 Вт. югары булган, йорт челтәрләреннән тәэмин ителә торган йорт яны территориясен яктырту лампалары, насос җиһазы (3 һәм күбрәк насос), лифтларның энергия бирү җиһазы һәм башка җиһаз | 6-9 | 1,44 |
| | | | | 10 һәм күбрәк | 1,54 |
| 3 | Лифтлар белән җиһазландырылмаган һәм җылыту чорында кайнар су белән тәэмин итү максатлары өчен электр белән ягу һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазландырылган күп фатирлы йортлар | 3.1. | Егәрлеге 40 Вт. кадәр булган лампалардан (подъезд эчендә һәм подъезд өстендә) файдаланып яктырту, электр белән тәэмин итү җайланмалары һәм башка җиһаз | - | 1,77 |
| | | 3.2 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр булган лампалардан (подъезд эчендә һәм подъезд өстендә), егәрлеге 60 Вт. югары булган, йорт челтәрләреннән тәэмин ителә торган йорт яны территориясен яктырту лампаларыннан файдаланып яктырту, электр белән тәэмин итү җайланмалары һәм башка җиһаз | - | 1,06 |
| 4 | Лифтлар белән җиһазландырылган һәм җылыту чорында кайнар су белән тәэмин итү максатлары өчен электр белән ягу һәм (яки) электр белән җылыту җайланмалары белән җиһазландырылган күп фатирлы йортлар | 4.1 | Энергия саклаучы лампалардан (подъезд эчендә һәм подъезд өстендә) файдаланып яктырту, электр белән тәэмин итү җайланмалары, лифтларның энергия бирү җиһазы һәм башка җиһаз | - | 1,15 |
| | | 4.2 | Егәрлеге 40 Вт. кадәр булган лампалардан (подъезд эчендә һәм подъезд өстендә) файдаланып яктырту, электр белән тәэмин итү җайланмалары, лифтларның энергия бирү җиһазы һәм башка җиһаз | - | 1,58 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2017 елның 28 июнендәге
3899 нчы карарына
3 нче кушымта

Социаль наем килешүләре һәм муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар, күп фатирлы йорт белән идарә итү алымын сайлау турында карар кабул итмәгән һәм гомуми җыелышта торак урыннарны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортларның торак милекчеләре өчен күп фатирлы йортта гомуми мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь ресурслар (салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү) өчен түләү күләме

| Т/с | Түләү исеме | Күп фатирлы йортлар категориясе | Этаж | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1. | Күп фатирлы йортның гомуми мөлкәтен карап тотканда кулланыла торган салкын су | Үзәкләштерелгән салкын һәм кайнар су, су җибәрү белән тәэмин ителгән күп фатирлы йортлар | 1-5 | аена гомуми торак мәйданының 1 кв. метрыннан | 0.07 |
| | | | 6-9 | | 0.06 |
| | | | 10-16 | | 0.07 |
| | | | 16 дан күбрәк | | 0.09 |
| 2. | Күп фатирлы йортның гомуми мөлкәтен карап тотканда кулланыла торган кайнар су | Үзәкләштерелгән салкын һәм кайнар су, су җибәрү белән тәэмин ителгән күп фатирлы йортлар | 1-5 | аена гомуми торак мәйданының 1 кв. метрыннан | 0.57 |
| | | | 6-9 | | 0.5 |
| | | | 10-16 | | 0.58 |
| | | | 16 дан күбрәк | | 0.74 |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Г.К. Әхмәтова